БОЛЬШЕМЕНГЕРСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ МӘҢГӘР АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422008, Республика Татарстан, Атнинский район, с.Большой Менгер, ул.Советская, д.8, т.3-46-25

# КАРАР

«04» март 2026 г. № 1

Олы Мәңгәр авыл җирлеге башкарма комитетының 01.10.2014 елның 7 номерлы «Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм территорияләр объектларына якын территорияләрне билгеләү турында» карарын үз көчен югалткан дип тану хакында.

1995 елның 22 ноябрендәге «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында»гы 171-ФЗ номерлы Федераль законына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 04.02.2026 елгы №02-08-03-2026/прдп56-26 күрсәтмәсе нигезендә Олы Мәңгәр авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итте:

1. Олы Мәңгәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 01.10.2014 елгы 7 номерлы «Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм территорияләр объектларына якын территорияләрне билгеләү турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы: Ф.Ф. Филатова